КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1501

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «2014 - 2025 елларга гомуми белем бирүне, инклюзивны да кертеп, үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче; 2019 ел, 6 июнь, 474 нче; 2019 ел, 31 октябрь, 974 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1246 нчы; 2020 ел, 24 июль, 618 нче; 2020 ел, 11 ноябрь, 1012 нче, 2020 ел, 3 декабрь, 1089 нчы; 2021 ел, 28 июнь, 512 нче, 2021 ел, 19 ноябрь, 1107 нче, 2022 ел, 15 июль, 680 нче, 2022 ел, 28 октябрь, 1147 нче карарлары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «2014 - 2025 елларга гомуми белем бирүне, инклюзивны да кертеп, үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль районнары өлешенең 53 процентка кадәр арттыру;

Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы гомуми белем бирү оешмалары өлешен 2,78 процентка кадәр арттыру;

Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы укучылар санын 271 кешегә кадәр арттыру»;

Ярдәмче программаның 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 34 пункт өстәргә:

«34. Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр геологик хәрәкәтен үстерү

2021/22 уку елы ахырына Татарстан Республикасының 22 муниципаль берәмлегендә гомуми белем бирү оешмалары базасында 38 геологик мәйданчык эшләде (республиканың гомуми белем бирү оешмалары санының 2,69 проценты). Яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәте тарафыннан кабул ителгән укучылар саны 248 кешегә җитте.

Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр геологик хәрәкәтен үстерү эше түбәндәге юнәлешләр буенча алып барыла:

мәктәпләрдә геолог һөнәрен популярлаштыру;

төп мәктәпләрдә командалар әзерләү;

яшь геологларның бөтенроссия һәм халыкара ярышларында катнашу өчен Татарстан Республикасы җыелма командасын формалаштыру эше;

яшь геологларның республика олимпиадаларын оештыру һәм уздыру.

Яшь геологларның һөнәри белемнәрен һәм дәрәҗәсен бәяләү өчен ел саен яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасы һәм яшь геологларның Бөтенроссия ачык кыр олимпиадасы уздырыла. Чараларны финанслау бюджеттан тыш чаралар, шул исәптән В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, кече нефть компанияләре исәбеннән гамәлгә ашырыла. Финанслау күләме «Татнефть» ГАҖ һәм республиканың кече нефть компанияләре тәкъдимнәренә нигезләнеп билгеләнә һәм ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Уңышлы нәтиҗәләргә ирешү күп яктан олимпиадага нәтиҗәле әзерлек моделен формалаштыруга ярдәм итә. Татарстан Республикасының һәр мәктәп командасына аны алып баручы кече нефть компаниясе беркетелгән, ул аларга минералогик коллекцияләр, маршрутлар һәм экскурсияләр өчен кирәкле геологик җиһазлар сатып алу, шулай ук урыннарга чыгуларны оештырганда методик ярдәм һәм ярдәм күрсәтү

өлешендә матди-техник ярдәм күрсәтә. Кече нефть компанияләреннән хәрәкәт кураторы булып «Нефтеконсорциум» ЯАҖ тора.

Һәр команда тренер укытучылар җитәкчелегендә шөгыльләнә. Казан (Идел буе) федераль университетының геология һәм нефть-газ технологияләре институты тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә махсус укыту-методик семинарлар һәм җыемнар үткәрелә.

Сәләтле балаларга ярдәм итү максатларында үткәрелә торган яшь геологларның Республика ачык кыр олимпиадасында катнашуга әзерлек чаралары, Россия геология фәненең иң яхшы традицияләрен пропагандалау түбәндәге таблицада китерелгән:

| Т/ Т/с | Чараның исеме | Сроклары |
|---|---|---|
| 1. | Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасының мәктәп этабы | ел саен октябрьдә |
| 2. | Геологик кейслар карары буенча «CASE - ЮГЕО» республика ачык чемпионаты | ел саен октябрьдә - ноябрьдә |
| 3. | Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасының муниципаль этабы | ел саен февральдә - мартта |
| 4. | Яшь геологларның Республика ачык кыр олимпиадасы ярышларына әзерлек буенча тренинглар | ел саен мартта - майда |
| 5. | Уку-тренировка җыеннары | ел саен майда |
| 6. | Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасында катнашу | ел саен июльдә |
| 7. | Шефка алынган оешмаларыны материаллар һәм җиһазлар белән | тәэмин итү, ел дәвамында |
| 8. | Экскурсия чаралары | ел саен көзге һәм кышкы каникул көннәрендә |
| 9. | Геологияне өйрәтү буенча база мәйданчыклары җитәкчеләренең йомгаклау конференциясе | ел саен октябрьдә - ноябрьдә |
| 10. | Казан (Идел буе) федераль университетының геология һәм нефть-газ технологияләре институтында геологик олимпиадаларга әзерлек алып баручы география укытучыларын өстәмә белем бирү үзәгендә укыту | ел саен сентябрьдә - майда»; |

ярдәмче программаның 5 бүлеге таблицасына түбәндәге эчтәлекле 62 – 64 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «62. | Яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль районнары өлеше, процент | | | | | | | | | | 51 | 53 | 53 |
| 63. | Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр | | | | | | | | | | 2,76 | 2,78 | 2,78 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрәкәтендә катнашучы гомуми белем бирү оешмалары өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| 64. | Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы укучылар саны, кеше | | | | | | | | | | 256 | 264 | 271»; |

1 нче ярдәмче программага кушымтаның «Бурыч исеме: гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның алга таба укуга һәм югары технологияле икътисадта эшчәнлеккә әзерлеген тәэмин итү өчен белем бирү һәм мәгариф мохите эчтәлеген модернизацияләү» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр геологик хәрәкәтен үстерү | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль берәмлекләр (килешү буенча), югары белем бирүче мәгариф оешмалары, ТР ССМ | 2023 – 2025 еллар | Яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль районнары өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 51 | 53 | 53 | | | | | | | | | | | | |
| | | | Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы гомуми белем бирү оешмалары өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 2,76 | 2,78 | 2,78 | | | | | | | | | | | | |
| | | | Татарстан Республикасында яшь геологларның балалар-яшүсмерләр хәрәкәтендә катнашучы укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 256 | 264 | 271». | | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин